| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ТИМЕРЛЕКСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ ТИМЕРЛЕК АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Чуваш Тимерлеге авылы КАРАР

№ 28 «18» декабрь 2019 ел

Тимерлек авыл җирлеге территориясендә 2020 елга хөкем ителгәннәргә административ җәза бирү өчен мәҗбүри эш төрләрен һәм оешмалар исемлеген билгеләү турында

«Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан мәҗбүри эш төрләрен һәм оешмалар исемлеген билгеләү турында» 16.11.2012 ел, ПР-43-6 номерлы Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы Президиумының карарын үтәү йөзеннән (Россия Федерациясе Административ хокук бозулар кодексына 2012 елның 8 июнендә кертелгән үзгәрешләргә бәйле рәвештә), мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза билгеләнгән затларны төзәтү, аларда нормаларга, җәмгыять кагыйдәләренә, иҗтимагый-файдалы хезмәткә ихтирамлы мөнәсәбәт булдыру максатларында), административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 32.13 статьясы нигезендә һәм законлы көченә кергән суд карары буенча административ җәза үтәү рәвешендәге мәҗбүри эшләрнең мәҗбүри хезмәт булып саналуын исәпкә алып, Тимерлек авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Хөкем ителүчеләр тарафыннан Тимерлек авыл җирлеге территориясе чикләрендә мәҗбүри эшләр башкару өчен мәҗбүри эшләр башкару урыннарын түбәндәгеләрне билгеләргә: Чуваш Тимерлеге авылында, Красномайский поселогында, (җинаять - башкарма инспекциясе белән килешү буенча).

2. Тимерлек авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри эшләр башкару өчен тиешле объект итеп - Тимерлек авыл җирлеге администрациясен (җинаять - башкарма инспекциясе белән килешенеп) билгеләргә.

3. Мәҗбүри эш төрләрен билгеләргә: торак пунктларны төзекләндерү, чистарту һәм яшелләндерү, зиратларны төзекләндерү, зиратларны чистарту, юл һәм буаларны чистарту, куаклыклар кисү, елгалар һәм чишмәләр территорияләрен санитар чистарту, юлларны һәм тышкы төзекләндерү буенча башка объектларны ремонтлау, йөк төяү – бушату эшләре, алдан һәм һөнәри әзерлек таләп итми торган башка хезмәт төрләре (җинаять-башкарма инспекциясе белән килешү буенча).

4. Әлеге карарны Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Нурлат районы буенча филиалы белән берлектә Тимерлек авыл җирлеге территориясендә яшәүче һәм төзәтү эшләренә хөкем ителгән затларга карата суд карарлары үтәлешен тәэмин итү өчен җибәрергә.

5. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Нурлат муниципаль районының «Интернет»челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Тимерлек авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе В.И.Гаврилов

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Тимерлек авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 18 декабрендәге 28 номерлы карарына
Килештерү кәгазе

«2020 елга мәҗбүри яки төзәтү эшләре төрләрен һәм 2020 елга төзәтү эшләре рәвешендә административ җәза бирелә торган оешмалар исемлеген билгеләү турында»
(документның исеме һәм атамасы)

«КИЛЕШЕНДЕ»

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Тимерлек авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе В.И. Гаврилов

«КИЛЕШЕНДЕ»

Татарстан Республикасы буенча
Россия ҖҮФХИ ФКУнең
Нурлат муниципальара филиалы начальнигы
эчке хезмәт майоры Р.Ф. Хамидуллин